**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**2017 елның 31 гыйнвары №46**

**;**

**«2016 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге бюджеты турында» 2015 елның 17 декабрендәге 12 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2016 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге бюджеты турында №22, 04.10.2016г. № 34, 2016 елның 16 декабрендәге 43 номерлы карарлар редакциясендә)**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең 81 статьясы һәм Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 18 декабрендәге 201 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «2016 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге бюджеты турында» 2015 елның 17 декабрендәге 12 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге советы карарына, түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып, кертергә:

1.1. 1 статьяда;

а) 1.1 пунктта « 6351,1» саннарын «6381,9» саннарына алмаштырырга

б) 1.2 пунктта «6507,1» санын «6567,8» санына алмаштырырга

в) 1.3 пунктта «156,0» санын «185,9» санына алмаштырырга

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 10.3,10.4 статьялары белән тулыландырырга:

«10.3 Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының Тәмте авыл җирлеге бюджетында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган, 2016 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп, 1257,6 мең сум күләмендә гамәлгә ашырыла торган бюджетара трансфертларны расларга.»

«10.4 Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге бюджетында башка дәрәҗәдәге органнар тарафыннан 2016 елда 627,1 мең сум күләмендә кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган бюджетара трансфертларны расларга.»

10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге бюджетында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан 1884,7 мең сум күләмендә кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар бар.

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының рәсми сайтында мәгълүмат такталарында басылып чыккан һәм урнаштырылган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәмте авыл җирлеге башлыгы И.А. Зиновьевка йөкләргә.

Тәмте авыл җирлеге башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе
И.Зиновьев